ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге
423078 Иске Ибрай авылы
Кооператив урамы, 2 йорт
тел. (факс) 884344- 4-63-72

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Совет Староибрайкинского
сельского поселения Аксубаевского
муниципального района
423078 с. Старое Ибрайкино
улица Кооперативная, д.2
тел. (факс) 884344-4-63-72

КАРАР

№64 2023 ел, 12 апрель

Җирле салымнар суммалары
өлешендә бурычны түләтүгә
ышанычсыз дип тануга өстәмә
нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәде, йә барлык варислар мирастан баш тартты һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын әйтмәсә.

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) милек хокукы туктатылган көннән соң өч ел вакыт узгач салым салу объекты булган мөлкәткә;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. Түбәндәге карарларны үз көчләрен югалткан дип танырга:

"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча недоимка һәм штрафлар буенча

бурыч түләнүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында» 05.03.2021 N 18 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге Советы карарына «Җирле салымнар буенча недоимканы һәм штрафлар буенча бурычларны түләп бетерүгә өстәмә нигезләр турында» Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының 05.03.2021 N 20 номерлы Иске Ибрай авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының 22.03.2021 N 20 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Ибрай авыл җирлегенең финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе, Аксубай
муниципаль районы Иске Ибрай авыл
җирлеге башлыгы: М.Г. Минигулов